ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17 нче йорт. Тел.3-44-44

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44

КАРАР
15.08.2019

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ПГ-39

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы

инвестиция декларациясен раслау турында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башлыгының 2014 елның 15 июлендәге ПГ-31 номерлы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының инвестицион декларациясен раслау турында» гы карары нигезендә, җирле үзидарә органнарының эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары белән үзара хезмәттәшлеге принципларын тәэмин итү һәм билгеләү максатыннан, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында инвестицион эшчәнлектә катнашучыларның үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында

Карар бирәм:

1.Татарстан Республикасының 2019 һәм аннан соңгы елларга инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген кушымта нигезендә расларга

2 Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://aktanysh.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча интернетның мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Актаныш муниципаль район Башлыгы Э.Н.Фаттахов

Расланган

Татарстан Республикасы
Актаныш Муниципаль районы
Башлыгының «15» 08 2019
№ПГ-39 санлы карары белән

2019 һәм аннан соңгы елларга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә тормышка ашыру планлаштырыла торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге

1. Тормышка ашыру өчен приоритетлы инвестицион проектлар:

1) «Ангус» токымлы мөгезле эре терлек үрчетү, сөт җитештерү. Проект куәте- елына 4500 бозау. Татарстан Республикасы Актаныш районы, Татар Ямалы авылының «су басу зонасы» территориясендә (“Актаныш мәрмәре” ҖЧҖ) 15 000 га көтүлекне үзләштерү планлаштырыла;

2) Шампиньон гөмбәләрен үстерү һәм компост җитештерү, елына 4133 тонна гөмбә һәм 12420 тонна компост җитештерү планлаштырыла. Актаныш авылында инновацион технологияләр кулланып эшләп килүче яңа предприятие төзү.